ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19 сентябрь, 2017 ел № 19/6

Шәһәр Советының аерым
Карарларына үзгәрешләр кертү
турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 28 июлендәге «Муниципаль берәмлек башлыкларының, депутатларның, хезмәт вазифаларын даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланып куелган вазифаи затларының, контроль хисап палатасы рәисләренең хезмәтенә түләүне һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазифаи окладларын индексацияләү турында» 585 санлы Карары, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Муниципаль вазифаларны даими нигездә башкаручы затларның хезмәтенә түләүне һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазифаи окладларын 2017 елның 1 октябреннән 1,049 тапкыр арттырырга (индексацияләргә).

2. Билгеләргә:

1) әлеге Карарның 1 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүне һәм вазифаи окладларын, шулай ук хезмәт хакын арттыру (индексацияләү) максатыннан айлык һәм башка төр өстәмәләрне түләүне башкарганда тиешле сумманы арту ягына өстәп, сумнарга кадәр түгәрәкләргә;

2) әлеге Карарның 1 пунктын гамәлгә ашыру бюджет чыгымнары кысаларында башкарыла.

3. Шәһәр Советының 2007 елның 23 гыйнварындагы «Яр Чаллы шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 28/7 санлы Карарын (Шәһәр Советының 2008 елның 23 гыйнварындаге 29/7, 2008 елның 25 сентябрендәге 34/16, 2009 елның 9 апрелендәге 40/23, 2012 елның 20 сентябрендәге 21/11,

2012 елның 20 декабрендәге 22/9, 2013 елның 29 августындагы 26/15, 2013 елның 31 октябрендәге 27/8, 2013 елның 19 декабрендәге 28/8 санлы Карарлары редакциясендә) 1 пунктын үзгәртеп, түбәндәгечә бәян итәргә;

«1. Башкарма комитет Җитәкчесеннән тыш муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладларын, биләгән муниципаль хезмәт вазифаларына бәйле рәвештә, түбәндәгечә билгеләргә

| муниципаль хезмәт вазифалары группасы | вазифаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль хезмәтнең югары вазифалары | 9 674 – 10 332 |
| Муниципаль хезмәтнең төп вазифалары | 6 570- 7 743 |
| Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазифалары | 5 463-6 070 |
| Муниципаль хезмәтнең өлкән вазифалары | 4 617-4 944 |
| Муниципаль хезмәтнең кече вазифалары | 2 555-4 140 |

Искәрмә: таблицада күрсәтелгән вазифаи окладның максималь күләме муниципаль хезмәт вазифалары группасындагы югары вазифаның вазифаи окладына туры килә.

Таблицада күрсәтелгән вазифаи окладның минималь күләме муниципаль хезмәт вазифалары группасындагы түбән вазифаның вазифаи окладына туры килә».

4. Шәһәр Советының 2008 елның 16 июнендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең вазифаи окладын билгеләү турында» 33/8 санлы Карарының (Шәһәр Советының 2008 елның 20 декабрендәге 22/9, 2013 елның 31 октябрендәге 27/8 санлы Карарлары редакциясендә) 1 пунктында «12 666 сум 00 тиен» сузләрен «13 287 сум 00 тиен» сүзләренә алыштырырга.

5. Әлеге Карарның 2017 елның 1 октябреннән гамәлгә керүен билгеләргә.

6. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев